СОВЕТ САРМАНОВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ САРМАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

15.11.2021 с. Сарманово № 59

**Сарман муниципаль районы Советының «Сарман муниципаль районы муниципаль махсуслаштырылган торак фондының торак урыннары бирү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2015 елның 16 февралендәге 191 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында**

«Россия Федерациясе Торак кодексына һәм торак-коммуналь хуҗалыкны реформалаштыруга ярдәм итү фонды турында» Федераль законга гражданнарны авария хәлендәге торак фондыннан күчерү өлешендә үзгәрешләр кертү турында» 2019 елның 27 декабрендәге 473-ФЗ номерлы Федераль законның 1 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы «Сарман муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Сарман муниципаль районы Советының «Сарман муниципаль районы муниципаль махсуслаштырылган торак фондыннан торак урыннары бирү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2015 елның 16 февралендәге 191 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 6 статьяның 6.1 пунктына түбәндәге эчтәлекле 6.1.4 пункт өстәргә:

«6.1.4. күпфатирлы йортны авария хәлендә һәм сүтелергә яки реконструкцияләнергә тиешле дип тану нәтиҗәсендә торак урыннары яшәү өчен яраксыз булган гражданнар;»

2) түбәндәге эчтәлекле 3_1 пункт өстәргә:

«6.2.4. әлеге Тәртипнең 6 статьясының 6.1.4 пунктында күрсәтелгән гражданнар белән исәп-хисаплар тәмамланганчы, яисә аларга торак урыннар бирелгәнче, әмма ике елдан да артык түгел;»

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) һәм Сарман муниципаль районының Интернет-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында https://sarmanovo.tatarstan.ru веб-адрес буенча урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Сарман муниципаль районы Советының экология мәсьәләләре һәм инфраструктура үсеше мәсьәләләре буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Сарман муниципаль районы
Совет Рәисе Ф.М.Хөснуллин